БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 07 2024 ел № 196

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 18 июнендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 665 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы» 434 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне 1 нче Кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә, яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларына түләү шартлары турындагы Нигезләмәне 2 нче Кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач район Башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы 283 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2019 елның 25 июнендәге «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы 283 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 243 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләр башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытка гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый, дип билгеләргә.

6. Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп:

Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә мөһим хезмәт шартларының үзгәрүе турында хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов